ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 24 статьясына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 24 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары составында Татарстан Республикасы милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан, кыйммәтле металларның һәм кыйммәтле ташларның дәүләт запасларын реализацияләүдән керемнәр һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчалар, шул исәптән Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары кимү, банк депозитларыннан акчаларны кире кайтарудан алына торган акчалар һәм банк депозитларына урнаштырыла торган акчалар арасындагы аерма расланган очракта, Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгы әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләрдән күрсәтелгән керемнәр суммасы, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчалар, шул исәптән Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары кимү чикләрендә, шулай ук банк депозитларыннан акчаларны кире кайтарудан алына торган акчалар һәм банк депозитларына урнаштырыла торган акчалар арасында уңай аерма чикләрендә артыграк булырга мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 03 март
№ 6-ТРЗ